**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**8 октябрь 2019ел** **№ 186**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2015 елның 24 ноябрендә 14 номерлы Карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына (2016 елның 10 октябрендәге 52 номерлы, 2017 елның 16 октябрендәге 93 номерлы, 2018 елның 12 мартындагы 121 номерлы, 2018 елның 14 сентябрендәге 140 номерлы карарлар белән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 22 статьяда:

а) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8) җирлек составына керә торган торак пунктта шушы торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;».

б) түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеш өстәргә:

3.1. Әлеге статьяда каралган гражданнар җыены анда торак пунктта яисә җирлектә яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия граждланнарның яртысыннан күбрәге катнашканда хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыгының бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаган очракта, әлеге Устав нигезендә гражданнар җыены гражданнар җыенын уздыру турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакыт эчендә этаплап уздырыла. Шул ук вакытта, гражданнар җыеның элеккеге этапларында катнашып, тавыш биргән затлар гражданнар җыеның алдагы этапларында тавыш бирүдә катнашмыйлар. Гражданнар җыенының карары гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмәтләр тактасында, шулай ук Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми сайтында (“авыл җирлекләре” бүлегендә) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырылганнан соң үз көченә керә.

Совет Рәисе
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина